СОВЕТ КЛЯУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.51, д.Пойкино, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422142

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЛӘҮШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Беренче май ур., 51 нче йорт, Пойкино авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422142

тел.(факс): (85563) 3-89-193; e-mail: Kls.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
от «20» февраль 2023 ел.

Карар
№ 2-22

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге № 1-32 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Территорияләрнең комплекслы үсешен тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге №494-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Келәүш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Келәүш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм уздыру тәртибе турында»1-32 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Кушымтаның 12 статьядагы 3 абзацын түбәндәге_ редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 3 пунктының 3.1 һәм 3.2 өлешләрендә билгеләнгән очраклардан тыш, җирлекләрнең генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында үткәрелә».

1.2. Кушымтаның 12 статьясындагы 2 абзацындагы «, шәһәр округы генераль планнары» сүзләрен төшереп калдырыга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге башлыгы Б.В.Ивановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Келәүш авыл җирлеге
Советы рәисе, җирлек башлыгы Б.В.Иванов